ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.03.2023 п.г.т.Алексеевское № 88

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен, гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 21.12.2018 ел № 470 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының бердәм торак Комиссиясен төзү турында» карары белән,

**карар бирәм:**

1. 2023 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен чик билгеләрен билгеләргә (Кушымта):

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым түләргә тиешле мөлкәтнең бәясе чиге:

1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 816 444 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 632 888 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 449 332 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 265 776 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 4 082 220 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 898 664 сум;

1.1.7. жиде кешедән торган гаилә өчен – 5 715 108 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 18 426 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 18 426 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешеле гаилә өчен – 18 426 сум;

2. Бердәм торак Комиссиясе әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларына таянып, гаиләнең һәр әгъзасының яки ялгыз яшәүче гражданның керемен

исәпләгәндә, аларны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ дип тану максатында эш итәргә тиеш.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның инфраструктура үсеше буенча җитәкчесе урынбасары М.Р. Гайсинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазифаларын башкаручы** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башкарма
комитетының 23.03.2023
№ 88 карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килгән керемнең чик кыйммәтләрен һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм 2023 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең бәясен билгеләүне исәпләү**

1. Алексеевск муниципаль районының уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешкә туры килгән торак бинаның бер квадрат метр мәйданының уртача базар бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

РПС = (Цп.р.+Цв.р.)/ni, монда:

РПС – торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече.«Россия Федерациясе буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метры уртача базар бәясе нормативын билгеләү методикасын раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 18.08.2021 № 584/пр боерыгы белән расланган Методика кулланыла (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән 17.02.2022 ел, 2022 елның 14 ноябре).

Цп.р. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында беренчел базарда торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача бәясе 57480 сум тәшкил итә. «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмасының уртача тәкъдиме, Алексеевск районы төзүчеләренең Инвестицион тораклары кулланылды.

Цв.р. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында икенчел базарда торак бинаның бер квадрат метр мәйданының уртача бәясе 1 кв.м өчен 33 237 сум тәшкил итә. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» НП ның 11.02.2023 ел, № 39 хаты нигезендә алынган мәгълүматлар кулланылды.

ni - сан күрсәткече (Цп.р., Цв.р.) торак бинаның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләрен исәпләгәндә кулланылган.

РПС = (57 480 + 33 237)/2 = 45 358 сум.

1. СЖ = НП х РС х РПС, монда

СЖ - базар бәясенең исәпләнгән күрсәткече яки милек бәясе чиге;

НП - бер гаилә әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РПС - торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача хисап буенча базар бәясе – 45 358 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 45 358 х 18 х 1 = 816 444 сум

б)ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 х 18 х 2 = 1 632 888 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 x 18 x 3 = 2 449 332 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 x 18 x 4 = 3 265 776 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 x 18 x 5 = 4 082 220 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 x 18 x 6 = 4 898 664 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 45 358 x 18 x 7 = 5 715 108 сум

3. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керемнең чик кыйммәте:

ПД =0,7 x СЖ x ПС/(1-(1 + ПС)$^{-КП}$)/(0,3 x РС), монда

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны сатып алуның базар бәясенең исәп хисап күрсәткече;

ПС - айлык кредит буенча процент ставкасы (8,2 % еллык яки 8,2/100/12 айга, беренчел взнос 20% шарты белән);

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (кредит бирү вакыты 15 ел яки 180 ай «Татарстан Республикасы Ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматлары буенча;

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләү нисбәте гаилә айлык кереме белән,

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 x 816 444 x (8,2/100/12)/ (1- (1 + (8,2/100/12))$^{-180}$) / (0,3 x 1) = 18 426 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 x 1 632 888 x (8,2/100/12)/ (1-(1 + (8,2/100/12))$^{-180}$) / (0,3 x 2) = 18 426 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 x 2 449 332 x (8,2/100/12)/ (1 (1 + (8,2/100/12))$^{-180}$) / (0,3 x 3) = 18 426 сум